**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 14 ноябре № 1167

«Җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 сентябрендәге 898 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә Кама Тамагы муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнарны милеккә түләүсез җир кишәрлекләре бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 898 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Гариза бирүченең формалаштырылган электрон формадагы запросының һәр юлын тутыру барышында, формат - логик тикшерү, органнар (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан, тутырылган электрон формадагы запросның хаталы юллары

ачыкланганда, ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе, гариза бирүчегә мәгълүмати хәбәр итү юлы белән җиткерелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И.А.Вязниковага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы М.Х. Хәбибуллова